**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.04.2021ел № 88

**Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында "Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 19.12.2016 елдагы № 433-ФЗ Федераль закон нигезендә (2017 елның 29 декабрендәге үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 08.06.2017 елдагы № 220 карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 кушымтаның 1 пунктындагы 4 абзацын төшереп калдырырга;

1.2. 3 кушымтаның 1 пунктындагы 18 абзацында «туу турында» сүзеннән соң «туу турында; "чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аларны нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә итү" җөмләсен өстәргә;

1.3. 3 кушымтаның 1 пунктындагы 21 абзацы "никах контракты" сүзеннән соң “никах контракты; чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыклар һәм аларны нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә итү” җөмләсен өстәргә;

1.4. 2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

“6) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар турында белешмәләр.»;

1.5. 2.6 пунктның 5 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Л. Халиковка йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Каюмов